ГЛАВА
НОВОБУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА БОРЫНДЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Борындык тимер юл станциясе поселогы

25.04.2025 № 4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 547-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге башлыгы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау Регламентына (09.04.2019 № 5, 24.03.2023 № 2, 13.10.2023 №4, 31.05.2024 №6 номерлы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.4 пунктта «Бердәм портал» сүзләреннән соң «яисә дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының гражданны идентификацияләүне һәм (яисә) аутентификацияләүне тәэмин итә торган башка мәгълүмат системасында» сүзләрен өстәргә;

2) 7.7.2 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгатькә җавап дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча йә гражданның Бердәм порталдагы яисә дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының башка мәгълүмати системасындагы адресы (уникаль идентификаторы) буенча, гражданның идентификациясен һәм (яисә) аны аутентицияләүне тәэмин итә торган электрон документ рәвешендә, Бердәм порталдан яисә башка мәгълүмати системадан файдаланганда һәм дәүләт органына, җирле

үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма формада җибәрелә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Борындык авыл
җирлеге башлыгы:



В.Г.Ранцев